АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.04.2026 п.г.т. Алексеевское № 50

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү хакындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск район Советының 21.07.2022 ел,№ 127 карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү хакындагы Нигезләмәнең 8,12 пунктлары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль**
**районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**